ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2020 г. Заинск №619

**«2021 елга үзгәрешләр белән «2017-2021 елларга Зәй муниципаль районының сәләтле балалары» программасын раслау турында» 2017 елның 18 августындагы 1486 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Зәй муниципаль районында мәгариф системасы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2017-2021 елларга Зәй муниципаль районының сәләтле балалары» программасын раслау турында» 2017 елның 18 августындагы 1486 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2017-2021 елларга Зәй муниципаль районының сәләтле балалары» программасы паспортындагы 5 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| **Программаны эшләү өчен нигезләр** | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы;<br>«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы;<br>«2015-2025 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 03 декабрендәге 943 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары; |

| | |
|---|---|
| | Бала хокуклары турында конвенция (1989 елның 20 ноябрендә БМО Генераль Ассамблеясенең 44/25 резолюциясе белән кабул ителгән);<br>Өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 04 сентябрендәге 1726-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган);<br>«Перспектива» Татарстан Республикасы балаларының һәм яшьләренең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм гамәлгә ашыру концепциясе (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 09 октябрендәге ПУ-862 номерлы Указы)<br>Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Сәләтле балаларга өстәмә белем бирү үзәге – мәктәп укучыларының фәннәр буенча кече академиясе» муниципаль бюджет учреждениесе уставы (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге 647 номерлы карары белән расланган). |

1.2. «2017-2021 елларга Зәй муниципаль районының сәләтле балалары» программасы паспортындагы 12 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| **Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары** | «2017-2021 елларга Зәй муниципаль районының сәләтле балалары» программасын финанслауның күләме, 2021 елга үзгәрешләр белән, 4 500 мең сум тәшкил итә:<br>2017 елга - 500 мең сум;<br>2018 елга - 500 мең сум;<br>2019 елга - 500 мең сум;<br>2020 елга - 500 мең сум;<br>2021 елга - 2 500 мең сум. |

1.3. «2017-2021 елларга Зәй муниципаль районының сәләтле балалары» программасының «Программага финанс ярдәме» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**Программага финанс ярдәме**

| | Чаралар | Гамәлгә ашыру срогы, ел. | Сумма, мең сумнарда | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Сәләтле укучыларга ярдәм итү һәм кызыксындыру чаралары:<br>-сәләтле укучыларга ярдәм итү буенча район башлыгының «Безнең өмет» гранты. | 2017<br>2018<br>2019<br>2020<br>2021 | 60,00<br>60,00<br>60,00<br>60,00<br>60,00 | Җирле бюджет |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Югары уку йортлары мөгаллимнәрен җәлеп итеп, фән олимпиадаларына әзерлек буенча сессияләр, мастер-класслар һәм башка чаралар үткәрүне оештыру.<br>Конкурсларда, фәнни-тикшеренү конференцияләрендә, төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда, укыту-тренировка җыеннарында катнашу, профильле лагерьларда булу. | 2017<br>2018<br>2019<br>2020<br>2021 | 340,00<br>340,00<br>340,00<br>340,00<br>340,00 | Җирле бюджет |
| 3 | Фәннәрнең кече академиясе хезмәткәрләренә өстәмә матди кызыксындыру | 2017<br>2018<br>2019<br>2020<br>2021 | 100,00<br>100,00<br>100,00<br>100,00<br>1800,00 | Җирле бюджет |
| 4 | Матди-техник базаны ныгыту | 2021 | 300,00 | Җирле бюджет |
| | Барысы | | 4500,00 | |

1.2. Карарны «Хезмәткәрләрне өстәмә матди кызыксындыру турында нигезләмә» кушымтасы белән тулыландырырга (кушымта).

2. «Өстәмә матди кызыксындыру турында» Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 15 ноябрендәге 1738 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галиев**

Л.Р. Печина
3-27-42

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «29» 12
619 номерлы карарына
кушымта

**Хезмәткәрләрне өстәмә матди кызыксындыру турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Сәләтле балаларга өстәмә белем бирү үзәге – Мәктәп укучылары фәннәренең кече академиясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләрен өстәмә матди кызыксындыру турында нигезләмә (алга таба - МБУДО «ЦДООД - МАНШ» ЗМР РТ) Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Россия Федерациясе Законы, «Сәләтле балаларга өстәмә белем бирү үзәге – Мәктәп укучылары фәннәренең кече академиясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге нигезләмә штат расписаниесе нигезендә «Сәләтле балаларга өстәмә белем бирү үзәге – Мәктәп укучылары фәннәренең кече академиясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесендә вазыйфа биләүче хезмәткәрләргә кагыла.

1.3. Әлеге нигезләмә буенча матди кызыксындыру дигәндә, җитәкче белән хезмәткәр арасында төзелгән контракт нигезендә, хезмәткәрләргә хезмәт килешүендә билгеләнгән вазыйфаи оклад күләменнән тыш өстәмә түләүләр рәвешендә акча түләүне аңларга кирәк.

1.4. Матди кызыксындыру «Сәләтле балаларга өстәмә белем бирү үзәге – Мәктәп укучылары фәннәренең кече академиясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең интеллектуаль иҗатка югары сәләтле бала шәхесе структурасында тикшерену һәм инновацион эшчәнлек доминанты формалаштырырдай шартлар тудыруда кызыксынуын көчәйтүгә юнәлдерелгән.

1.5. Матди кызыксындыру һәр хезмәткәрнең хезмәтен индивидуаль бәяләү һәм аның ТР ЗМР «ЦДООД - МАНШ» муниципаль бюджет учреждениесенең устав бурычларын һәм килешү йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә керткән шәхси өлеше нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2. Өстәмәләрнең күләме

2.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Сәләтле балаларга өстәмә белем бирү үзәге – Мәктәп укучылары фәннәренең кече академиясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләрен матди кызыксындыру «2017-2021 елларга Зәй муниципаль районының сәләтле балалары» программасында каралган чаралар кысаларында гамәлгә ашырыла.

2.2. «Сәләтле балаларга өстәмә белем бирү үзәге – Мәктәп укучылары фәннәренең кече академиясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләрен өстәмә кызыксындыру күләмнәре:

2.2.1. Педагогик хезмәткәрләрне өстәмә матди кызыксындыру күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып педагогик хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора (таблица 1).

Таблица 1

Педагогик хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары буенча үлчәүле коэффициентларның иң чик җыелма күләме

| № п/п | Критерийның исеме | Үлчәү берәмлеге | Үлчәү ешлыгы | Исәп-хисап тәртибе |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Олимпиадаларда катнашу | Җиңүчеләр/ призерлар | Елга бер мәртәбә | **1. «Олимпка юл» республика олимпиадасында җиңүчеләр һәм призерлар**<br>1.1 «Олимпка юл» республика олимпиадасында 1 җиңүче/призер – 5 балл;<br>1.2 «Олимпка юл» республика олимпиадасында 2-3 җиңүче/призер – 10 балл;<br>1.3. «Олимпка юл» республика олимпиадасында 4 һәм аннан күбрәк җиңүче/призер – 15 балл.<br>**2. Мәктәп укучыларының республика олимпиадасында җиңүчеләр һәм призерлар**<br>2.1. Республика мәктәп укучылары олимпиадасының 2-3 җиңүчесе/призеры - 20 балл;<br>2.2. Республика мәктәп укучылары олимпиадасының 1 җиңүчесе/призеры - 30 балл;<br>2.3. Республика мәктәп укучылары олимпиадасының 4 һәм аннан күбрәк җиңүчесе/призеры - 40 балл;<br>**3. Укучыларның Бөтенроссия олимпиадасында җиңүчеләр һәм призерлар**<br>3.1. Укучыларның Бөтенроссия олимпиадасында 1 җиңүче/призер (региональ этап) - 30 балл; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | 3.2. Укучыларның Бөтенроссия олимпиадасында 2-3 җиңүче/призер (региональ этап) – 40 балл;<br>3.3. Укучыларның Бөтенроссия олимпиадасында 4 һәм аннан күбрәк җиңүче/призер (региональ этап) – 50 балл;<br>3.4. Укучыларның Бөтенроссия олимпиадасында җиңүче/призер (йомгаклау этабы) - 60 бал. |
| 2. | Кече фәннәр академиясе кысаларында сәләтле балалар белән эшләү (укучылар ның казаныш лары) | Чаралар | Елга бер мәртәбә | -халыкара дәрәҗәдәге чараларда катнашу нәтиҗәләре буенча (I-III) урыннар - 25 балл;<br>- федераль дәрәҗәдә - 20 балл;<br>-республика/төбәк дәрәҗәсендәге - 15 балл. |

2.2.2. Педагогик хезмәткәрләргә беренче эш елында: сәләтле балалар белән эшләгән өчен - уку елы дәвамында хезмәт хакының 10 проценты.

2.2.3. Инновацион белем бирү технологияләрен гамәлгә керткән өчен, аерып әйткәндә, түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырган өчен:

- учреждениенең инновацион эшчәнлегенең эчтәлеген, структурасын һәм нәтиҗәләрен проблемалы анализлау;
- педагогик фән һәм практика вәкилләре арасындагы хезмәттәшлекне координацияләү;
- инновацион программалар эшләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру, педагогик хезмәткәрләргә инновацион программалар һәм технологияләр үзләштерүдә һәм эшләүдә ярдәм итү;
- укучылар контингентын саклау буенча чаралар күрү;
- педагог-тәҗрибәчеләрнең эшен координацияләү;
- учреждениенең тәҗрибә-эксперимент эшчәнлегендә катнашуы (стажировка, база, экспериментал мәйданчыклар, алдынгы югары уку йортлары һәм мәгариф вәкилләре белән хезмәттәшлек итү турында килешүләр);
- учреждениене квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү, аларның һөнәри белемнәрен үстерү, тәҗрибә алмашуга ярдәм итү;
- белем бирүдә үзебезнең һәм чит ил тәҗрибәсенең яңа техникаларын һәм технологияләрен куллану;
- белем бирү процессының фәнни һәм укыту-методик тәэмин ителеше сыйфатын анализлау һәм тикшереп тору;

- "Сәләтле балалар" муниципаль программасы эшчәнлеге юнәлешләрен координацияләү;

ай саен: окладның директорга – 75%, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасарына – 60%, методистка – 50% күләмендә түләү.

## 3. Өстәмәләрне раслау һәм исәпләү тәртибе

3.1. «Сәләтле балаларга өстәмә белем бирү үзәге – Мәктәп укучылары фәннәренең кече академиясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренә өстәмәләр күләме әлеге нигезләмәгә таянып, агымдагы уку елына, матди кызыксындыру буенча комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә директор приказы белән билгеләнә.

3.2. Өстәмә түләүләр, фактта эшләнгән сәгатьләрне исәпкә алып, хезмәткәрләргә төп хезмәт хакы белән ай саен түләнә, алар иминият кертемнәрен исәпләү базасына, уртача хезмәт хакы исәбенә, отпуск өчен түләү исәбенә керә.

3.3. Хезмәткәргә өстәмә түләүне бирмәү яисә өлешчә генә бирү директор боерыгы белән, дисциплинар җәза нигезендә, мәхрүм итү яки киметелү сәбәпләре күрсәтелеп, башкарыла.

## 4.Йомгаклау

4.1. Матди кызыксындыру турында әлеге нигезләмәнең тексты «Сәләтле балаларга өстәмә белем бирү үзәге – Мәктәп укучылары фәннәренең кече академиясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең барлык хезмәткәрләренә дә җиткерелергә тиеш.